БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь 2019 ел № 221

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Балтач муниципаль районы бюджетыннан Балтач муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Балтач муниципаль районы бюджетыннан Балтач муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2019 елның 17 декабрендәге
221 номерлы карарына
кушымта

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Балтач муниципаль районы бюджетыннан Балтач муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү Тәртибе**

Субсидияләр Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары белән раслана торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен үтәүне финанслашу максатларында бирелә торган, субсидияләр исемлеге нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү максатларында бирелә.

Субсидияләр бирү шартлары, җирлекләр арасында субсидияләр бирү һәм аларны бүлү өчен җирлекләрне сайлап алу критерийлары Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен билгели торган яки субсидияләр бирүнең элек расланган кагыйдәләренә үзгәрешләр кертә торган норматив хокукый актлар проектлары эшләнә.

Субсидияләр бирү кагыйдәләре түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидияләрне бирү шартлары;

в) субсидияләр бирү өчен җирлекләрне сайлап алу критерийлары. Финанслашуы субсидияләр хисабына гамәлгә ашырыла торган чараларны гамәлгә ашыруга җирлек тарафыннан күрсәтелгән акчалар күләмен субсидияләр бирү өчен җирлекләрне сайлап алу критерие сыйфатында файдалану рөхсәт ителми;

г) субсидия күләмен җирлекнең тиешле чараларын (халык санынннан (халыкның аерым төркемнәреннән - социаль хезмәт күрсәтүләрне соңгы алучылардан) һәм (яисә) җирлектә тиешле чараларны (объектлар төзүгә) һәм (яисә) башка критерийларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны сан ягыннан бәяләүдән чыгып) финанслауга пропорциональ ихтыяҗны билгеләүне күздә тоткан һәм җирлекнең Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан чыгым йөкләмәләрен финанслауның иң чик дәрәҗәсен исәпкә алып, субсидияләрне җирлекләр бюджетлары арасында бүлү методикасы;

д) субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлек бюджетына субсидияләр бирү турындагы килешүдә (алга таба - килешү)

билгеләнә торган субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре исемлеге;

е) килешү шартларын үтәмәгәндә җирлекләрнең финанс җаваплылыгы чараларын куллану нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән җирлекләргә субсидияләр бирү шартларын һәм субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалану буенча йөкләмәләрне үтәмәгән очракта субсидияләрне киметүнең тәртибе һәм чик күләме.

Җирлекләр бюджетлары арасында субсидияләр бүлгәндә финанс елында җирлек бюджетына субсидия күләме, финанслашу максатларында, җирлекнең субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен финанс елында үтәү өчен акчалар күләменнән артмаска тиеш.

Субсидияләрнең максатчан билгеләнеше, субсидияләр бирү кагыйдәләре белән һәм җирлекләренең финанслашулары өчен субсидияләр каралган чыгым йөкләмәләреннән чыгып, килешүләр белән билгеләнә.

Субсидияләр бирүнең шартлары сыйфатында субсидияләр бирү кагыйдәләре белән түбәндәгеләр карала:

а) финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль хокукый актлар булу.

б) аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә, Балтач муниципаль районы бюджетыннан бирелергә планлаштырылган күләмне дә кертеп, җирлек бюджетында җирлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә, аларны финанслашу максатларында субсидия бирелә торган, бюджет ассигнованиеләре булу.

в) финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча җирлек йөкләмәсен күздә тота торган килешү төзү һәм күрсәтелгән килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

Субсидияләр бирү килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Советының агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты турында карарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының хокукый актына тиешле финанс елында субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен төгәлләштерүне күздә тоткан үзгәрешләр кертелгән очракта, килешүгә тиешле үзгәрешләр кертелә.

Субсидия исәбеннән финанслана торган җирлек бюджетының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме килешүнең билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә (нәтиҗәләренә) ирешү зарурлыгыннан чыгып, җирлек бюджеты турында карар белән раслана.

Җирлек тарафыннан субсидия бирү елының 31 декабренә килешүдә каралган йөкләмәләрне бозуга юл куелса һәм күрсәтелгән бозулар бетерелмәгән очракта, акчалар кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияне максатсыз файдаланган һәм (яисә) җирлек тарафыннан аны бирү шартларын бозган очракта, шул исәптән җирлек тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына акчаларны кире кайтармау очрагында, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.